МИНИСТЕРСТВО ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

17.01.2018 Казан шәһәре № под-69/18

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет турында Положениене раслау турында» 2015 елның 1 июнендәге 6536/15 номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Министрлык, Дәүләт комитеты, Татарстан Республикасы ведомствосы каршындагы Иҗтимагый совет турында» 2010 елның 18 ноябрендәге 906 нчы карары нигезендә б о е р а м:

1. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет турында Положениене раслау турында» 2015 елның 1 июнендәге 6536/15 номерлы боерыгына (2015 елның 14 сентябрендәге под-9277/15 номерлы, 2016 елның 6 июнендәге под-1115/16 номерлы боерыклар белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Боерык преамбуласында «(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 елның 15 октябрендәге 856 номерлы, 2013 елның 24 октябрендәге 793 номерлы, 2014 елның 20 сентябрендәге 669 номерлы, 2015 елның 14 маендагы 341 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән)» сүзләрен төшереп калдырырга;

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет турында приказ белән расланган Положение:

1.2 пунктын «Министрлык, Дәүләт комитеты, Татарстан Республикасы ведомствосы каршындагы Иҗтимагый совет төзү тәртибе нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан расланган» сүзләрен өстәргә;

3 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Иҗтимагый совет составы

3.1.Иҗтимагый совет составы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан расланган, Министрлык, Дәүләт комитеты, Татарстан Республикасы ведомствосы каршында Иҗтимагый совет оештыру тәртибе нигезендә формалаштырыла.

3.2.Иҗтимагый совет, Министрлык тарафыннан, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы белән берлектә, аның составында 15 кеше ирекле катнашу нигезендә төзелә.

3.3.Министрлык Иҗтимагый совет составы расланганнан соң 30 көннән дә соңга калмыйча Иҗтимагый советның беренче утырышын үткәрүне оештыра, анда аның әгъзалары арасыннан Иҗтимагый совет рәисе һәм рәис урынбасары сайлана. Карар ачык тавыш бирү юлы белән Иҗтимагый совет әгъзаларының гомуми саныннан күпчелек тавыш белән кабул ителә.

3.4.Иҗтимагый совет рәисен яисә рәис урынбасарын вазыйфасыннан азат итү мәсьәләсе Иҗтимагый совет тарафыннан министр мөрәҗәгате буенча, шулай ук Рәис яисә рәис урынбасарының шәхси гаризасы буенча яисә Иҗтимагый совет әгъзаларының гомуми саныннан кимендә биштән бер өлешен тәшкил итүче төркем тәкъдиме буенча карала. Карар Иҗтимагый совет әгъзаларының гомуми санының күпчелек тавышы белән кабул ителә.

3.5.Иҗтимагый совет рәисе Иҗтимагый совет әгъзалары арасыннан Иҗтимагый Советның җаваплы секретарен билгели.

3.6.Иҗтимагый совет әгъзаларының вәкаләтләре срогы иҗтимагый советның яңа формалашкан составының беренче утырышын үткәрү көненнән башлап өч ел тәшкил итә.

3.7.Иҗтимагый совет әгъзасы вәкаләтләре башкарма орган боерыгы нигезендә Иҗтимагый совет рәисе тәкъдиме буенча түбәндәге очракларда туктатыла:

Россия Федерациясенең җинаять-процессуаль законнарында билгеләнгән тәртиптә җинаять кылуда гаепләү белдерү;

административ арест рәвешендә административ җәза билгеләү;

дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) органы депутатына кандидат, җирле үзидарә органында сайлау вазыйфасына кандидат, ышанычлы зат яисә сәяси партия кандидатының вәкаләтле вәкиле сыйфатында, шулай ук Россия Федерациясендә референдум үткәрү буенча инициатив төркем составына кергән очракта.

3.8.Иҗтимагый совет әгъзасы вәкаләтләре түбәндәге очракларда туктатыла:

вәкаләтләре срогы чыкса;

үз теләге белән Иҗтимагый совет составыннан чыгу турында гариза бирсә;

сәламәтлеге буенча Иҗтимагый совет эшендә катнашу мөмкинлеге булмаса;

аңа карата чыгарылган суд карары үз көченә кергәч;

аны эшкә яраксыз дип тану, закон көченә кергән суд карары нигезендә яисә билгесез сәбәпләр аркасында Иҗтимагый совет утырашларына йөрмәү;

утырышта катнашкан Иҗтимагый совет әгъзалары саныннан күпчелек тавыш белән иҗтимагый совет карары нигезендә кабул ителгән этик нормаларны тупас бозу;

иҗтимагый совет утырышлары эшендә системалы рәвештә сәбәпсез катнашмау (өч тапкырдан артык);

иҗтимагый совет рәисе яисә рәис урынбасарының күрсәтмәләрен даими (ике тапкырдан артык) сәбәпсез үтәлмәү;

Россия Федерациясенең дәүләт хезмәтенә, Россия Федерациясенең дәүләт гражданлык хезмәтенә, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең башка субъектлары дәүләт хезмәтенә, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең башка субъектлары дәүләт гражданлык хезмәтенә, муниципаль хезмәткә яисә муниципаль хезмәт вазыйфаларын башкаруга билгеләнүе;

чит ил гражданлыгы алу;

Россия Федерациясе гражданлыгы туктатылу.

3.9.Иҗтимагый совет әгъзасы вәкаләтләрен туктату Министрлык боерыгы нигезендә, Иҗтимагый совет әгъзасының язма гаризасы яки аның Рәисе яисә Иҗтимагый совет рәисе урынбасары тәкъдиме нигезендә, шулай ук әлеге Положениенең 3.8 пунктында каралган хәлләрне ачыклау очрагында гамәлгә ашырыла.

Иҗтимагый совет әгъзасы әлеге Положениенең 3.8 пунктындагы дүртенче, бишенче, унынчы, унберенче абзацларында каралган шартлар барлыкка килү турында Иҗтимагый совет рәисенә яисә рәис урынбасарына хәбәр итәргә тиеш;

5.4 пунктының өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Иҗтимагый совет карарлары гади күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышлар тигезләшкән очракта Иҗтимагый совет рәисенең тавышы хәлиткеч булып тора.»;

5.12 пунктын түбәндәге эчтәлек белән тулыландырырга:

“5.12. Иҗтимагый совет үз эшендә Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы әгъзалары катнашуын тәэмин итә.»;

5.14 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.14. Иҗтимагый совет эшчәнлеген оештыру-техник яктан тәэмин итүне министрлык башкара.».

2. Юридик бүлеккә әлеге боерыкны билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы юстиция Министрлыгына дәүләт теркәвенә җибәрергә.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны министрның беренче урынбасары А. И. Поминовка йөкләргә.

Татарстан Республикасы Премьер-
министры урынбасары – министр Р.Т.Бурганов